СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.08.2022 пос. Октябрьский 21-117

«Югары Ослан муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең Ключищи авыл китапханәсен бетерү мәсьәләсе буенча Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы халкы - гражданнардан сораштыру билгеләү һәм үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының 2013 елның 29 мартындагы 28-135 номерлы карары белән, (26.05.2021 ел, 9-52 номерлы үзгәрешләр белән) Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында яшәүчеләрнең фикерен ачыклау максатыннан, «Югары Ослан муниципаль районы Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең Ключищи авыл китапханәсен бетерү мәсьәләсе буенча,

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы территориясендә яшәүче гражданнардан сораштыру үткәрү билгеләргә.
2. 2022 елның 14 августында көндезге чорда 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр гражданнардан сораштыру үткәрү билгеләргә.
3. Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы халкы өчен сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауның түбәндәге формулировкасын расларга: «Югары Ослан муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең Ключищи авыл китапханәсен бетерү фикере белән килешәсезме?»

4. Сораштыру үткәрү кәгазьләрен тутыру рәвешендә гражданнардан сорашып белешү үткәрү методикасын расларга (1-нче кушымта).
5. Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында яшәүчеләрдән сораштыру үткәрү комиссиясе составын расларга (2-нче кушымта).
6. Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы халкының сораштыру үткәрү кәгазе формасын расларга (3-нче кушымта).
7. Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы өчен сораштыру үткәрүдә катнашучы халыкның минималь санын - 65 кешене билгеләргә.
8. Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылының бөтен территориясен гражданнардан сораштыру үткәрү территориясе итеп билгеләргә.
9. Сораштыру үткәрү урыны итеп түбәндәге пунктларны расларга:

   - Ключищи авылы чиркәве янындагы мәйдан (Үзәк ур., 21 нче йорт)
   - Кибет янындагы мәйдан (Колхоз урамы, 95 нче йорт)
   - гражданнарның яшәү урыны буенча.

10. Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы халкына Октябрьский авыл җирлегенең рәсми сайтында игълан урнаштыру юлы белән гражданнардан сораштыру үткәрү турында хәбәр итү тәртибен Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча расларга:

    – Ключищи авылы, кибеттә белдерүләр тактасы: Колхозная ур., 95 нче йорт;
    – Ключищи авылы, кибеттә белдерүләр тактасы: Үзәк ур., 22А йорты;
    – Ключищи авылы, пристаньдагы белдерүләр тактасы: Волжская урамы

    Шулай ук 18 яшькә җиткән Ключищи авылы халкына язмача хәбәр бирү юлы белән.

11. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
12. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе Советының даими комиссиясенә йөкләргә;

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль
районы Октябрьский авыл
җирлеге Советының 2022
елның 2 августыннан 21-117
номерлы карарына
1 номерлы кушымта

Сораштыру үткәрү кәгазьләрен тутыру рәвешендә гражданнардан сорашып белешү үткәрү методикасы

1. Сораштыру үткәрүнең максаты: «Югары Ослан муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең Ключищи авыл китапханәсен бетерү турында карар кабул иткәндә Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы халкының фикерен ачыклау.
2. Сораштыру үткәрү объекты: Октябрьский авыл җирлегенең, сайлау хокукына ия Ключищи авылы халкы. Сораштыруда катнашучы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы халкының минималь саны сайлау хокукына ия халыкның кимендә 50 процентында билгеләнгән, бу 65 кеше тәшкил итә.
3. Мәгълүмат җыю методлары: мәгълүматны җыю сораштыру үткәрү пунктларында, шулай ук сораштырыла торган халыкның яшәү урыны буенча сораштыру кәгазен тутыру юлы белән башкарыла.

Гражданнардан сорашып белешүне гамәлгә ашыруга комиссия муниципаль берәмлекнең башка халкын җәлеп итәргә мөмкин. Гражданнардан сорашып белешүне гамәлгә ашыручы затларның исемлеген комиссия төзи һәм үз карары белән сорашып белешүне үткәрү датасына кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча раслый.

Яшәү урыны буенча гражданнардан сораштыру уздырганда сорашып белешүче затны сораштыруда чыгарылган сорау һәм сораштыру кәгазен тутыру тәртибе белән таныштырырга тиеш. Сораштыру кәгазе ала торган шәхесне һәм яшәү урынын раслаучы документ күрсәткәч, сораштыру кәгазендә сораштыру датасын күрсәтә, үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, яшәү урынын, туган көнен тулысынча күрсәтә, үз ихтыяры белән белдерүе буенча сораштыру кәгазендә «Сорау» варианты «риза» яки «риза түгел» графасында үз имзасын куя, шулай ук икенче имза белән «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152 –ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын раслый һәм сораштыруны гамәлгә ашыручы затка тутырылган сораштыру кәгазен кире кайтара. Сораштыруны башкаручы зат тутырылган сораштыру кәгазенә имза сала, датасын, фамилиясен, исемен, әтисенең исемен күрсәтә.

Сораштыру үткәрү кәгазен тутырганда карандаш куллану рөхсәт ителми.

Сораштыру үткәрү пунктларында, шулай ук сорашып белешүдә катнашучыларның яшәү урыны буенча сорашып белешүдә катнашучылар исемлеге, тутырылган сораштыру кәгазьләре, сораштыру кәгазьләренең калган чиста бланклары сораштыруны гамәлгә ашыручы затлар, комиссия әгъзаларына җибәрелә.

4. Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы территориясендә яшәүче гражданнардан сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорау Октябрьский авыл җирлеге халкының «Югары Ослан муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең Ключищи авыл китапханәсен бетерү мәсьәләсе буенча фикеренә кагыла.
5. Сораштыру нәтиҗәләрен эшкәртү сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауга респондентлар сайлаган җавапларның вариантлары санын, аннары бертөрле фикерләре булган респондентлар өлешен билгеләү ысулы белән башкарыла.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль
районы Октябрьский авыл
җирлеге Советының 2022
елның 2 августыннан 21-117
номерлы карарына
2 номерлы кушымта

Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы территориясендә яшәүче гражданнардан сораштыру үткәрү комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| Азизов Ш.Р. | - | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгы |
| Карасева Н.А. | - | "Югары Ослан муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы" МБУ директоры |
| Гафуров И.М. | - | 6 нчы Ключищи сайлау округы буенча Октябрьский авыл җирлеге Советы депутаты |
| Янгуразова А.Р. | - | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре |
| Сиражиева С.А. | - | Ключищи авылы кешесе (килешү буенча) |
| Минкина З.Г. | - | Ключищи авылы кешесе (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советының 2022 елның 2 августыннан 21-117 номерлы карарына 3 номерлы кушымта

«Югары Ослан муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең Ключищи авыл китапханәсен бетерү турында карар кабул итү өчен Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы халкын сораштыру кәгазе

| Сораштыру датасы | Сораштыруда катнашучы ф. и. о. | Сораштыруда катнашучының туган көне | Сораштыруда катнашучының яшәү адресы | Сорау: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең Ключищи авыл китапханәсен бетерү белән килешәсезме?<br><br>Җавап вариантлары:<br>риза / риза түгел | Сораштыруда катнашучының имзалары |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 ст.таләпләре нигезендә Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы гражданнарын сораштыру процедурасын тәэмин итү максатыннан Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы гражданнарын автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларыннан файдаланмыйча, ә нәкъ менә 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга ризалык бирәм.

Эшкәртүгә мин ризалык бирә торган шәхси мәгълүматларга: фамилиясе, исеме, атасының исеме; туу датасы, адресы һәм гамәлдә булу вакытын чикләмичә, гражданнарны сораштыру белән бәйле башка мәгълүматлар керә.

Барлык гамәлләрне (операцияләрне) минем шәхси мәгълүматларым белән, шул исәптән җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, куллануны, блоклауны, юкка чыгаруны да кертеп, гамәлгә ашыру хокукын бирәм. Оператор минем шәхси мәгълүматларны аларның электрон белешмәләр базасына кертү, исемлекләргә (реестрларга) кертү һәм хисап формаларына хисап белешмәләре (документлар) бирүне регламентлаштыручы документлар белән каралган хисап формалары ярдәмендә эшкәртергә һәм аларны вәкаләтле органнарга тапшырырга хокуклы.

Әлеге ризалык язма рәвештә аңа имза салган көннән алып гамәлдә була. Мин үземнең язма гаризасым нигезендә ризалыгымны кире кайтару хокукы турында белүемне раслыйм.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны раслыйм: _________ ____________________________________/___________________________

(дата) (имза) (имзаны киңәйтеп язу)

Сораштыруны гамәлгә ашыручы затның имзасы _____________________________/___________________________________

(дата) (имза) (имзаны киңәйтеп язу)